СОВЕТ НИЖНЕШАНДЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1, с. Зюри,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422153

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ШҮЛӘҢГЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 1 нче йорт, Җөри авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422153

тел.(факс): (85563) 3-87-31; e-mail: Nsnd.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

От 29 апреля 2019 г. № 1-41

“Түбән Шүләнгер авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге 1-31 санлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге”муниципаль берәмлегетерриториясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге Советы карары турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 ел, 06 октябрь, 131 - ФЗ санлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Мамадыш районы прокуратурасының 2019 елның 26 февралендәге тәкъдимнәре һәм 2019 елның 29 апрелендә уздырылган ачык тыңлаулар нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципальрайоны Түбән Шүләнгер авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Түбән Шүләнгер авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге 1-31 санлыкарары белән расланган “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә(17.09.2018 ел, 2-34 нче санлы редакциядә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1.Кагыйдәләрнең 2 бүлегенең 13 бүлеген түбәндәге эчтәлекле 56 пунктбелән тулыландырырга:

“ 56. Юридик затлар (шәхси эшмәкәрләр) һәм физик затлар Сосновский балтырганының таралу чыганакларын ачыклау, үзләренең милкендә биләүдә яки куллануда булган җир участокларында Сосновский балтырганын бетерү (юк итү), аннан арындыру, бетерү (юк итү) буенча мөстәкыйль рәвештәүз хисабына системалы чаралар үткәрергә тиеш, (Сосновский балтырганын бетерү (юк итү) буенча чаралар аларбөреләнгәнче һәм чәчәк ата башлаганга кадәр үткәрелергә тиеш)”.

1.2. Кагыйдәләрнең 3 бүлегендәге 26 нчы бүлекнең 171 пунктын түбәндәге эчтәлекле 8 пунктча белән тулыландырырга:

“Сосновский балтырганының таралу чыганакларын ачыклау, үз милекләрендә булган җир кишәрлекләрен дә бетерү (юк итү), буенча чаралар юридик затларның (шәхси эшмәкәрләрнең) һәм физик затларның үз акчалары хисабына мөстәкыйль рәвештә Сосновский балтырганыбөреленгәнче һәм чәчәк ата башлаганчы үткәрелергә тиеш.”

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге башлыгына Е.М.Михайловага йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Шүләнгер авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /Е.М.Михайлова/

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Түбән Шүләнгер
авыл җирлеге Советының
29.04.2019 ел, 1-41 нчы санлы карарына
кушымта №1

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге 1-31 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гражданнарның
тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге 1-31 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәре түбәндәге адрес буенча:422153, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Түбән Шүләнгер авылы, Совет урамы, 7 нче А йорт , яисә 885563(38731)тел/факс;e-mail: Nsnd.Mam@tatar.ru буенча язма рәвештә, үзенең Ф.И. А.и. , туган елын , яшәү урынын күрсәтеп, төзәтмәләрне кертеп, Түбән Шүләнгер авыл җирлеге Советына таблица формасында тапшырыла:

| № | Пункт, пунктча | Проект карарының тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәләр исәпкә алынган проект тексты | Төзәтмәләрнең авторы, (Ф.И.А.и., адресы, эш яки уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә, әлеге карар игълан ителгән көннән 8 сәгатьтән 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

1.Халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар (заявкалар) чыгыш хокукы белән түбәндәге адрес буенча бирелә:422153, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Түбән Шүләнгер авылы, Мәктәп урамы, 2 нче йорт, тел. (885563)38731, e-mail: Nsnd.Mam@tatar.ru. Гаризалар эш көннәрендә, халык тыңлаулары үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, 8 сәгатьтән 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Гражданнарның тәкъдимнәре эш төркеме тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Түбән Шүләнгер авыл җирлеге Советына һәм муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла.